МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

_____________________№_______________

На №__________ _____от_______________

**Руководителям отделов (управлений) образования Исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан**

О проведении VIII межрегионального
открытого конкурс-фестиваля имени
Сары Садыковой «Калфаклы сандугач»

Во исполнение государственной программы Республики Татарстан «Сохранение национальной идентичности татарского народа (2014-2016 годы)», в целях приобщения обучающихся к творческому наследию татарского композитора С.Садыковой, освоения традиций татарской национальной музыки, выявления одаренных, талантливых детей Министерством образования и науки Республики Татарстан совместно с Исполкомом Всемирного конгресса татар, Союзом композиторов Республики Татарстан и Управлением образования г. Казани **30 октября 2015 года** проводится VIII межрегиональный открытый конкурс-фестиваль имени Сары Садыковой «Калфаклы сандугач» (далее – Фестиваль).

Для участия в Фестивале приглашаются обучающиеся детских музыкальных школ, детских школ искусств и общеобразовательных организаций Республики Татарстан и субъектов Российской Федерации.

Для участия в Фестивале необходимо **до 20 октября 2015 года** направить заявку на участие по электронной почте: gimn-4-kir@yandex.ru, G4.kzn@tatar.ru с пометкой «Фестиваль» с указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Ответственность за жизнь и здоровье школьников в пути следования и во время мероприятия необходимо возложить на сопровождающих педагогов.

Место проведения Фестиваля: 420102, г. Казань, ул. Г. Баруди, д. 3А.

Контактный телефон: 8(843) 554-40-01.

Приложение: положение на 3 л. в 1 экз.

**Заместитель Премьер-министра
Республики Татарстан – министр** **Э.Н. Фаттахов**

А.Р. Гильманшина
(843) 294-95-10



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Кушымта

**Укучылар өчен Сара Садыйкова исемендәге «Калфаклы сандугач – 2015» татар җыры һәм музыка уен коралларының VIII төбәкара ачык конкурс-фестивален үткәрү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми мәгълүмат

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе, Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә белем бирүче 4 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе һәм Казан шәһәре Киров районы «24 нче музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү учреждениесе белән берлектә күренекле татар композиторы Сара Садыйкова иҗатына багышланган «Калфаклы сандугач» конкурс-фестивален (алга таба – Фестиваль) үткәрә.

2015 нче елда фестиваль сигезенче тапкыр үткәрелә. Быел ул композитор С.Садыйкованың тууына 109 ел тулу һәм С.Садыйкованың кызы Әлфия Айдарскаяга 90 яшь тулу уңаеннан «Татар халкының яраткан композиторы С.Садыйкованың кызы Ә.Айдарскаяга – 90 яшь» девизы астында узачак.

## 2. Фестивальнең максаты:

- Төрле төбәкләрдә яшәүче балаларны «Татар сандугачы», композитор С.Садыйкова әсәрләрен өйрәнүгә, татар сәнгатенә җәлеп итү;
- Татарстан Республикасы халкы һәм шулай ук чит төбәкләрдә яшәүче балаларның талантын ачу, укучыларның башкару сәләтләрен үстерү, татар композиторы С.Садыйкова иҗатын тирәнтен өйрәнү;
- татар милли музыкасы аша укучыларга мәдәни һәм әхлак тәрбиясе бирү.

## 3. Катнашучылар

«Калфаклы сандугач» төбәкара ачык конкурс-фестивалендә Татарстан Республикася һәм Россия Федерациясе төбәкләреннән 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге музыка, сәнгать һәм гомуми белем бирүче мәктәп укучылары катнашырга мөмкин.

## 4. Фестивальне оештыручылар

- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы.
- Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты
- Татарстан Республикасы Композиторлар Берлеге

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе.
- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе
- Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары мәгариф бүлеге.
- Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә белем бирүче 4 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе.
- Казан шәһәре Киров районы «24 нче музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

## 5. Фестивальне оештыру һәм үткәрү тәртибе

«Калфаклы сандугач» конкурс-фестивале **2015 нче елның 30 октябрендә** үткәрелә. Конкурста катнашырга теләүчеләр 20 нче октябрьдән дә соңга калмыйча, оештыру комитетына анкета-гаризалар җибәрергә тиеш.

5.1. Фестиваль яшь аралыгы буенча 3 төркемгә бүленеп үткәрелә: 7-10 яшьлек, 11-14 яшьлек, 15-17 яшьлек балалар.

5.2. Номинацияләр:

- **солистлар** (вокал, инструментта башкаручы);
- **вокаль ансамбле** (дуэт, трио һ.б.);
- **инструменталь ансамбль** (кечкенә дуэтлар, трио; уртача – квартетлар, квинтетлар; катнаш);

5.3. Конкурс-фестивальдә катнашучыларның тәртип номеры гаризалар килү вакытында төзелә.

5.4. Фестивальдә катнашу өчен, **2015 елның 20 октябренә кадәр** оештыру комитетына түбәндәге адрес буенча анкета-гаризалар җибәрелерергә тиеш: 420102, Казан шәһәре, Чкалов урамы, 8 нче йорт. Тел/факс 8(843)554-40-01.

Электрон адрес: gimn-4-kir@yandex.ru

5.5. Оештыру комитеты катнашучыларны репетиция заллары белән тәэмин итә.

5.6. Фестивальдә җырны башкару фонограмассыз булырга тиеш.

## 6. Конкурс-фестивальнең эш тәртибе

08:30-09:30 Фестивальдә катнашучыларны теркәү (регистрация)

10:00-10:15 Конкурс-фестивальнең ачылу тантанасы.

10:30-13:00 Конкурс-фестивальдә катнашучылар чыгышы.

13:00-14:00 Төшке аш.

14.00-16:30 Конкурс-фестивальдә катнашучылар чыгышы

16:30 Фестивальнең ябылу тантанасы, җиңүчеләрне котлау.

17:00 Конкурс лауреатларының Гала-концерты.

### 7. Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү

Фестивальдә катнашкан барлык укучыларга да Министрлыкның дипломнары тапшырыла. Нәтиҗәләр буенча боерык әзерләнә.

**Белешмәләр өчен адреслар һәм телефоннар:**

Электрон почта адресы: gimn-4-kir@yandex.ru

420102, Казан шәһәре, Чкалов урамы, 8 нче йорт. Телефон/факс: 8 (843) 554-40-01; 89196810333 (милли эшләр буенча директор урынбасары Гөлфия Мансур кызы Габдрахманова)

### Сара Садыйкова исемендәге «Калфаклы сандугач – 2015» татар җыры һәм музыка уен коралларының VIII төбәкара ачык конкурс-фестивалендә катнашу өчен гариза

| | |
|---|---|
| Хронометражы күрсәтелгән башкару программасы (Мәсәлән, С.Садыйкованың бер әсәре яки аның җырының инструменталь эшкәртмәсе) | |
| Номинация | |
| Башкаручының фамилиясе, исеме, (тулы килеш)<br>Концертмейстрның фамилиясе, исеме,әтисенең исеме (тулы килеш) | |
| Башкаручының (ансамбльнең) яше | |
| Ансамбльнең составы, башкаручылар саны | |
| Оешма (устав буенча), адрес һәм телефон | |
| Катнашучының телефоны | |

Оешма җитәкчесенең имзасы

«________» ____________________________________ 2015 ел.

Лист согласования к документу № исх-1065/15 от 19.08.2015
Инициатор согласования: Исмагилова А.Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 17.08.2015 10:59

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 19.08.2015 - 08:14 | - |
| 2 | Ахметзянова Л.М. | | Согласовано 19.08.2015 - 10:17 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 19.08.2015 - 11:30 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Подписано 19.08.2015 - 16:24 | - |